# КАРАР

22 ноябрь 2024 ел

№2

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Октябрино авылында 2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Октябрино торак пунктында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары,18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр; 18 яшькә кадәрге балаларын тәрбияләүче ялгыз әниләр; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәкләр; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Октябрино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә узара салым кертергә
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау(килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм Октябирно авылында технадзорны гамәлгә ашыру; энергияне саклый торган лампаларны сатып алу, урнаштыру Октябрино авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар һәм башка төр урамнарны яктырту, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру);

-су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау(су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манараларын ремонтлау, тоту, материаллар сатып алу, урнаштыру һәм китерү, су күтәрү манараларын, Октябрино авылының Урман урамындагы артезиан скважинасы өчен насослар ,килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, шул исәптән Октябрино авылының Урман урамында артезиан скважиналарын куллануга лицензия алу өчен документлар пакетын һәм лаборатория тикшеренүләрен әзерләү буенча чаралар);

- коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү(коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм Октябрино авылында технадзорны гамәлгә ашыру);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Октябрино авылының Урман урамында янгын гидрантларын һәм комплектлаучы детальләрне сатып алу һәм урнаштыру ,килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру);

- һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (һәйкәлләр территорияләрен төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм Октябрино авылында технадзорны гамәлгә ашыру);

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Октябрино авылының ташлы һәм асфальт түшәлгән юлларын төзү, төзекләндерү, Октябрино авылының урам-юл челтәрен карап тоту, җәйге вакытта территорияне кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, ягулык-майлау материаллары җитештерү һәм килешүгә шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру);

-торак пункт территориясен төзекләндерү (төзү, ремонтлау, аларга якын территорияләрне төзекләндерү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру);

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймаларны төзү, төзекләндерү (зират территориясен төзекләндерү,ремонтлау, материал сатып алу һәм урнаштыру, койманы ремонтлау, инвентарь сатып алу, Октябрино авылының Урман урамындагы зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелек)

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Өркеш авыл җирлеге башлыгы: А.Ш.Әгъләмова